**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КРАСНОСЕЛЬСКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**
422700, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Биектау тиемер юл станциясе поселогы, Совет ур., 13

**ГЛАВА КРАСНОСЕЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422700, Республика Татарстан, Высокогорский район, п. ж/д ст. Высокая Гора, ул. Советская, 13

тел./факс 8(84365) 2-35-82, e-mail: Ksel.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**29 ноябрь 2021 ел** **№ 4**

**Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенең «Каменка» шифаханәсе поселогы, Новый Поселок поселогы, Киндери тимер юл разъезды поселогы, Березовка поселогы, Урманчы поселогы торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыены билгеләп кую турында.**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Уставының 24 статьясына таянып, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү:

1.1. 2021 елның 10 декабрендә 13 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенең «Каменка» шифаханәсе поселогы торак пунктында, «Каменка» шифаханәсе поселогы, Нагорная урамы, 3 йорт адресы буенча (трансформатор будкасы янында);

1.2. 2021 елның 10 декабрендә 13 сәгать 30 минутта Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенең Новый Поселок поселогы торак пунктында, Новый Поселок поселогы, Лесная урамы, 1А йорт адресы буенча (водокачка янында);

1.3. 2021 елның 10 декабрендә 14 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенең Киндери тимер юл разъезды поселогы торак пунктында, Киндери тимер юл разъезды поселогы, Киндери подстанциясе урамы, 14 йорт янында;

1.4. 2021 елның 10 декабрендә 14 сәгать 30 минутта Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенең Березовка поселогы торак пунктында, Березовка поселогы, Центральная урамы, 8 йорт янында.;

1.5. 2021 елның 10 декабрендә 15 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенең Урманчы поселогы торак пунктында, Урманчы поселогы, Светлая урамы, 31 йорт адресы буенча (балалар бакчасы янында).

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2.1. «Каменка» шифаханәсе поселогы торак пунктында: «2022 елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенең «Каменка» шифаханәсе поселогы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга

- «Каменка» шифаханәсе поселогында янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү (янгын гидрантлары)

белән килешәсезме

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

2.2. Новый Поселок поселогы торак пунктында:

2.2.1 «2022 елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенең Новый Поселок поселогы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга

- Новый Поселок поселогында урам яктырту челтәрләрен төзү, ремонтлау һәм карап тоту

белән килешәсезме

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

2.2.2 Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенең Новый Поселок поселогы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы 2020 елның 5 декабрендәге 1 нче номерлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү.

2.3. Киндери тимер юл разъезды поселогы торак пунктында «2022 елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенең Киндери тимер юл разъезды поселогы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга

- Киндери тимер юл разъезды поселогы Киндери подстанциясе урамында су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу челтәрләрен төзү һәм ремонтлау

- Киндери тимер юл разъезды поселогы Станционная урамында контейнер мәйданчыкларын, павильоннарны карап тоту

белән килешәсезме

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

2.4. Березовка поселогы торак пунктында: «2022 елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенең Березовка поселогы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга

- Березовка поселогында балалар мәйданчыгын сатып алу һәм төзекләндерү
- Березовка поселогында контейнер мәйданчыкларын карап тоту

белән килешәсезме

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

2.5. Урманче поселогы торак пунктында: «2022 елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенең Урманче поселогы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга

- Урманчы поселогында су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу челтәрләрен төзү һәм ремонтлау (су башняларын тоту)

белән килешәсезме

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм җирлекнең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Биектау муниципаль районы
Красносельский авыл җирлеге башлыгы урынбасары Р.Р.Никитенко